КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 май г.Казань № 640

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 апрель, 237 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең һәм «Түбән Кама үзәк район күпюнәлешле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең паллиатив медицина ярдәме бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен өстәмә айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартларына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең һәм «Түбән Кама үзәк район күпюнәлешле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең паллиатив

медицина ярдәме бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен өстәмә акчалата түләүләр турында" 2015 ел, 10 апрель, 237 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 декабрь, 1131 нче, 2018 ел, 12 май, 347 нче, 2019 ел, 17 октябрь, 914 нче, 2020 ел, 13 июль, 585 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең һәм «Түбән Кама үзәк район күпюнәлешле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең паллиатив медицина ярдәме бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен өстәмә айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартларына, 2 пунктның беренче абзацында «сигез мең сум» сүзләрен «унике мең биш йөз сум» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин